ГЛАВА БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

«01» 08 2026 г.

**КАРАР**

№ 182

**Татарстан Республикасы Балтач район Советында гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау һәм гражданнарны шәхсән кабул итүне тәэмин итү буенча эш Тәртибенә үзгәрешләр кертү турында**

Балтач районы прокуратурасы тарафыннан Балтач муниципаль район Башлыгының 2021 елның 3 июнендәге 143 номерлы карарына (2024 елның 26 декабрендәге үзгәрешләр белән) 2026 елның 26 маендагы 02-08-2026/ Прдп187-26-20920011 номерлы протестны карап һәм «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турындагы» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 28 декабрендәге 547-ФЗ номерлы Федераль законга, «Татарстан Республикасы гражданнары мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына таянып, Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә Балтач муниципаль район Башлыгы карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балтач район Советында гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау һәм гражданнарны шәхсән кабул итүне тәэмин итү буенча Балтач муниципаль район Башлыгының 2021 елның 3 июнендәге 143 номерлы карары белән расланган эш Тәртибенә (2024 елның 26 декабрендәге 376 номерлы карар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Тәртипнең 1 бүлегендәге 1.1 пунктының 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Әлеге тәртип Россия Федерациясе гражданнарының язма һәм телдән мөрәҗәгатьләрен (алга таба - мөрәҗәгать) кабул итү, исәпкә алу, теркәү, карау кагыйдәләрен, шулай ук электрон документ формасында, шул исәптән «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) Бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасын (алга таба - Бердәм портал), җирле үзидарә органының башка мәгълүмат системасын яисә җирле үзидарә органының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге гражданнарны идентификацияләү яисә аутентификацияләүне тәэмин итә торган рәсми сайтын кулланып, шулай ук гражданның җирле үзидарә органына телдән мөрәҗәгатен, тәкъдим, гариза яисә шикаятен карауны һәм үтәүне тикшереп тору тәртибен, мөрәҗәгатьтә булган мәгълүматны анализлау һәм гомумиләштерү, мөрәҗәгатьләрнең сәбәпләрен һәм характерын ачыклау тәртибен, шулай ук Балтач район Советында гражданнарны кабул итүне оештыруны билгели.»;

1.2. Тәртипнең 2 бүлегендәге 2.14 пунктының 3 өлешендә беренче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Мөрәҗәгатькә җавап электрон документ рәвешендә район Советына яисә вазыйфаи затка электрон документ формасында кергән мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән электрон почта адресы буенча, Бердәм порталны яисә башка мәгълүмати системаны кулланган очракта бердәм порталда яисә гражданны идентификацияләү яисә аутентификацияләүне тәэмин итә торган дәүләт органының яисә җирле үзидарә органының шәхси кабинет адресы (уникаль идентификаторы) буенча, район советына яисә вазыйфаи затка язма рәвештә кергән мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән почта адресы буенча язма рәвештә җибәрелә.»;

1.3. Тәртипнең 4 бүлегендәге 4.4 пунктының 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) I, II төркем инвалидлар, инвалид балалар һәм мондый балаларны озатып йөрүче затлар;»;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (http://baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар имза салынган көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Балтач район Советы аппараты җитәкчесенә йөкләргә.

Балтач муниципаль
район Башлыгы

Р.Р.Нотфуллин